МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 62/о

ПРИКАЗ

БОЕРЫК

«11» 04 2018

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2017 елның 10 ноябрендәге 179/о номерлы боерыгы белән расланган «Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 процenttан артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм

мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 10 ноябрендәге 179/о номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2017 елның 27 декабрендәге 229/о номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

**Министр** **И.Ә.Фәйзуллин**

ОТДЕЛ ОРГАНИЗАЦИОННО-ПРОТОКОЛЬНОЙ РАБОТЫ КОНТРОЛЯ И ДЕЛОПРОИЗВОДСТВА

Татарстан Республикасы Төзелеш,
архитектура һәм торак-коммуналь
хуҗалык министрлыгының 2018
елның 11 апрелендәге 62/о номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 10 ноябрендәге 179/о номерлы боерыгы белән расланган Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган
үзгәрешләр

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 10 ноябрендәге 179/о номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2017 елның 27 декабрендәге 229/о

номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Финанслануы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасын, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар, устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 проценттан артык булган юридик затлар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы капиталь төзелеш объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәл булу-булмавына тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. «ТР ДЭБХИ» ДАУ урнашкан урыны, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турында мәгълүмат:

Юридик адресы: 420073, Россия, ТР, Казан ш., Шуртыгин ур., 22.

Урнашкан урын адресы: 420054, Россия, ТР, Казан ш., Габдулла Тукай ур., 125.

«ТР ДЭБХИ» ДАУ элемтә телефоннары:

Казан шәһәре коды: 8 (843);

«ТР ДЭБХИ» ДАУ башлыгы: 272-04-94;

«ТР ДЭБХИ» ДАУ башлыгы урынбасары: 520-70-50 (өст. 401);

техник хезмәт җитәкчесе: 272-65-14 (өст. 209);

экспертиза хезмәте җитәкчесе: 241-02-19 (өст. 204);

проект-смета документациясен кабул итү бүлеге: 272-56-84 (өст. 230);

бәяләмәләр белән эшләү һәм бирү бүлеге: 272-65-14 (өст. 213);

бухгалтерия исәбенә алу, хисаплылык һәм финанслар бүлеге: 272-65-60 (өст. 248);

кадрлар бүлеге: 241-02-14 (өст. 241).

«ТР ДЭБХИ» ДАУ электрон почта адресы: expertiza-rt@tatar.ru.

«ТР ДЭБХИ» ДАУ турында кирәкле барча мәгълүмат Интернет-сайтларда бар:

expert.kgts.ru

gosekspertiza-rt.ru

госэкспертиза-рт.рф

gosekspertiza.tatarstan.ru

Гаризаларны һәм бүтән документларны дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кабул итү һәм бәяләмәләр бирү вакыты:

Дүшәмбе-пәнҗешәмбе: 08.00-17.00;

Җомга: 08.00-15.45;

Шимбә, якшәмбе – ял көннәре;

Төшке аш вакыты: 12.30-13.15.

«ТР ДЭБХИ» ДАУ бинасына керү кертү кәгазе һәм (яисә) шәхес таныклаучы документ буенча гамәлгә ашырыла.

Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4, 1.5, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11 һәм 6.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне үз эченә ала.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат түбәндәгеләрдә урнаштырыла:

Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru);

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында (http://www.minstroy.tatar.ru);

«ТР ДЭБХИ» ДАУ сайтында (http://www.gosekspertiza.tatarstan.ru);

«ТР ДЭБХИ» ДАУ телдән яисә язмача рәвештә (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә».»;

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының 2.13 пунктында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гарызнамә ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә»;

3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.11 пунктын өстәргә:

«3.11. Бәяләмәне үзгәртеп рәсмиләштерү элегрәк бирелгән бәяләмәдә җибәрелгән техник хаталарны бетерүгә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

Бәяләмәне үзгәртеп рәсмиләштерү теркәлгән гариза нигезендә гамәлгә ашырыла, анысы ирекле рәвештә (5 нче кушымтадагы үрнәктә), төзәтелергә тиешле хаталарны күрсәтеп тапшырыла. Гаризага дәүләт хезмәтен күрсәтүнең нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган бәяләмәләрнең нөсхәләре һәм мөрәҗәгать итүченең техник заказчы (төзүче) исеменнән эш йөртү вәкаләтләрен раслый торган документ теркәлә.

3.11.1. «ТР ДЭБХИ» ДАУ белгече:

техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм теркәүгә ала;

гариза «ТР ДӘБХИ» ДАУ башлыгы тарафыннан каралганнан соң, башлык бәяләмәгә үзгәрешләр кертү яисә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында җавап әзерләү турындагы резолюция имзалый, башкару өчен җаваплы белгеч билгели.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәүгә алынган, җаваплы белгечкә башкару өчен тапшырылган гариза.

3.11.2. Җаваплы белгеч:

«ТР ДЭБХИ» ДАУ башлыгының бәяләмәгә үзгәрешләр кертү турында яисә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында боерык проектын әзерли;

«ТР ДЭБХИ» ДАУ башлыгының боерык проектын килештерү өчен «ТР ДЭБХИ» ДАУ башлыгына (ул булмаганда аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затка) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза бүлеккә җибәрелгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: килештерү өчен «ТР ДЭБХИ» ДАУ

башлыгына җибәрелгән боерык проекты.

3.11.3. «ТР ДЭБХИ» ДАУ башлыгы (ул булмаганда – аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат) бәяләмәне үзгәртеп рәсмиләштерү турында яисә бәяләмәгә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында боерыкны раслый. Имзаланган боерык җаваплы белгечкә җибәрелә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура проект раслау өчен килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бәяләмәне үзгәртеп рәсмиләштерү турында яисә бәяләмәгә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында карар.

Бәяләмәгә үзгәрешләр кертү турында карар кабул ителгән очракта, белгеч мөрәҗәгать итүчегә, техник хатаны төзәтү турында гаризада яисә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, бәяләмәнең әзер булуы турында хәбәр итә һәм мөрәҗәгать итүченең теләгенә карап:

әгәр мөрәҗәгать итүче шәхсән үзенең алу теләген белдергән булса, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәне тапшыру датасын һәм вакытын хәбәр итә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар беренче бәяләмәгә үзгәрешләр кертелгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче белән бәяләмәне алу ысулын килештерү.

Үзгәрешләр кертүдән баш тарткан очракта, мөрәҗәгать итүчегә язмача җавап бирелә.

3.11.4. Мөрәҗәгать итүчегә техник хатасы төзәтелгән дәүләт хезмәте нәтиҗәсен тапшыру.

Җаваплы белгеч, мөрәҗәгать итүченең ихтыярына карап, бәяләмәне яисә бәяләмәгә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында җавапны тапшыра (җибәрә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүчедән җибәрелгән хата турында гариза алынган көннән соң биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә техник хатасы төзәтеп тапшырылган бәяләмә.»;

4-5 бүлекләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту тәртибе һәм рәвешләре**

4.1. «ТР ДЭБХИ» ДАУ вазыйфаи затлары тарафыннан шушы Регламентның нигезләмәләре һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актларның үтәлүен һәм башкарылуын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы тикшереп тору эше тиешле административ процедураны башкару өчен җаваплы булган зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Агымдагы тикшереп тору «ТР ДЭБХИ» ДАУ вазыйфаи затларының шушы Регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору, гариза тапшыручыларның хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгать итүчеләрнең «ТР ДЭБХИ» ДАУ вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләү.

4.4. «ТР ДЭБХИ» ДАУ актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавына тикшерүләр уздырыла.

Тикшерүләр планлы («ТР ДЭБХИ» ДАУ яртыеллык яисә еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

4.5.1. әлеге Регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актларның таләпләре бозылуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

4.5.2. физик һәм юридик затлар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы «ТР ДЭБХИ» ДАУ вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында үзләренең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр теркәлә.

4.7. Тикшереп тору нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, Россия Федерациясе законнары нигезендә гаепле затларны җаваплылыкка тарту гамәлгә ашырыла.

4.8. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә «ТР ДЭБХИ» ДАУ эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

**5. «ТР ДЭБХИ» ДАУ, шулай ук вазыйфаи затларның карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе**

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы «ТР ДЭБХИ» ДАУ вазыйфаи затларының (хезмәткәрләренең) гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә «ТР ДЭБХИ» ДАУ җитәкчесенә шикаять белдерергә хокуклы.

«ТР ДЭБХИ» ДАУ җитәкчесе кабул иткән карарларга (гамәлләргә) шикаятьләр Министрлыкка министрның тикшерүдә тотучы урынбасары исеменә яисә министр исеменә, министр урынбасары (министр) тарафыннан кабул ителә торган карарларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына яисә монополиягә каршы органга шикаять белдерелергә мөмкин.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта буенча, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://minstroy.tatarstan.ru/), «ТР ДЭБХИ» ДАУ рәсми сайты (http://gosekspertiza.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы

вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.6. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документларның исемлеге китерелә.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән язу һәм басма хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң бер көн узганчы мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»;

6 бүлекне көчен югалткан дип танырга.